**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 2 июнендәге 1879 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 29 маендагы 1529 номерлы карары**
**белән расланган «Молодежный» территориясенең**
**бер өлешен планлаштыру проектына үзгәреш кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 1529 номерлы карары белән расланган «Молодежный» территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 25 апрелендәге 1181 номерлы, 2024 елның 1 августындагы 3253 номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге 5360 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), планлаштыру проектының аерым өлешен әлеге карарга кушымта нигезендә раслап, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 2 июнендәге
1879 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 29 маендагы 1529 номерлы карары белән расланган**
**«Молодежный» территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына**
**кертелә торган үзгәреш**

III «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә» бүлегендә 8 пунктны яңа редакциядә бирергә:

«8. Чик параметрлар

16:16:120601:7485 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан 4 номерлы торак йорт өчен Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары нигезендә 90 машина урыны урнаштыру таләп ителә. Проект буенча 91 машина урыны (шул исәптән, исәпләнгәннәргә өстәмә буларак, вакытлыча саклау өчен 1 машина урыны) урнаштыру күздә тотыла, шулардан:

- 63 машина урыны – 16:16:120601:7485 кадастр номерлы җир кишәрлеге яссылыгында;
- 18 машина урыны – 16:16:120601:7693 кадастр номерлы җир кишәрлеге яссылыгында;
- 10 машина урыны – 16:16:120601:24596 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан, 363 машина урынына исәпләнгән ачык яссы автомобильләр кую урынында.

16:16:120601:7514 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан 5 номерлы торак йорт өчен Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары нигезендә 235 машина урыны урнаштыру таләп ителә. Проект буенча 239 машина урыны (шул исәптән, исәпләнгәннәргә өстәмә буларак, вакытлыча саклау өчен 4 машина урыны) урнаштыру күздә тотыла, шулардан:

- 57 машина урыны – 16:16:120601:7514 кадастр номерлы җир кишәрлеге яссылыгында;

- 102 машина урыны – 16:16:120601:24596 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан, 363 машина урынына исәпләнгән яссы парковка территориясендә;

- 80 машина урыны – 16:16:120601:7692 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан, 499 машина урынына исәпләнгән күпкатлы паркингта. Күпкатлы паркинг төзелеше башланганчы һәм аны төзү чорында 80 машина урынын 9 номерлы торак йорт төзелеше өчен билгеләнгән 16:16:120601:23878 кадастр номерлы җир кишәрлегендәге вакытлыча парковкаларда урнаштыру күздә тотыла.

16:16:120601:23879 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан 8 номерлы торак йорт өчен Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары нигезендә 523 машина урыны урнаштыру таләп ителә. Проект буенча 523 машина урыны урнаштыру күздә тотыла, шулардан:

- 143 машина урыны – 16:16:120601:23879 кадастр номерлы җир кишәрлеге яссылыгында;

- 178 машина урыны – җир асты паркингында;

- 202 машина урыны – 16:16:120601:7692 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан, 499 машина урынына исәпләнгән күпкатлы паркингта. Күпкатлы паркинг төзелеше башланганчы һәм аны төзү чорында 202 машина урынын 9 номерлы торак йорт төзелеше өчен билгеләнгән 16:16:120601:23878 кадастр номерлы җир кишәрлеге яссылыгында урнаштыру күздә тотыла.

16:16:120601:23878 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан 9 номерлы торак йорт өчен Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары нигезендә 522 машина урыны урнаштыру таләп ителә. Проект буенча 522 машина урыны урнаштыру күздә тотыла, шулардан:

- 142 машина урыны – 16:16:120601:23878 кадастр номерлы җир кишәрлеге яссылыгында;

- 180 машина урыны – җир асты паркингында;

- 200 машина урыны – 499 машина урынына исәпләнгән күпкатлы паркингта.

16:16:120601:7692 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан, 499 машина урынына исәпләнгән күпкатлы паркингның эчкә кертеп төзелгән биналары өчен Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары нигезендә 10 машина урыны урнаштыру таләп ителә. Проект буенча 27 машина урыны урнаштыру күздә тотыла, шулардан:

- 6 машина урыны – 16:16:120601:7692 кадастр номерлы җир кишәрлеге яссылыгында;

- 4 машина урыны – 16:16:120601:7693 кадастр номерлы җир кишәрлеге яссылыгында;

- 17 машина урыны – күпкатлы паркингта.

Торак фондын файдалануга тапшыру вакытына, биредә яшәүчеләрнең җиңел автомобильләрен даими саклауны тәэмин итү максатыннан, файдалануга тапшырыла торган торак фондының тиешле күләме өчен шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары белән каралган саннан ким булмаган санда машина урыннары җиһазландырылырга тиеш. Бу машина урыннары, урам-юл челтәренең кызыл линияләреннән һәм планлаштыруның әлеге проекты белән гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләрне һәм социаль инфраструктура һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру каралган территорияләрдән тыш, территорияне планлаштыруның әлеге проектын әзерләү чикләрендә урнаштырылырга тиеш.

Гамәлдәге проект карарларының килештерелгән нигезләмәләре, капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылышларга рөхсәтләр нигезендә проект белән төзелешне җайга салу линияләре (кызыл линияләрдән ераклыклар) нигезендә билгеләнә торган җир кишәрлекләре чикләреннән минималь ераклыклар билгеләнә.

Территорияне планлаштыру проекты сызымнарында күпкатлы торак төзелеше объектларын план буенча урнаштыру зонасында күпфатирлы торак йортларны төзүне җайга салу линиясе күрсәтелде.

Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымнарында китерелгән төзелешне җайга салу линияләре төзелеш проектын һәм планлаштырыла торган сервитутларны исәпкә алып билгеләнде».